КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 гыйнвар г.Казань № 35

2021 – 2024 елларга Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү концепциясен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 номерлы карары белән расланган «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 – 2024 елларга Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү концепциясен (алга таба – Концепция) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләүнең, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы трансформацияләүнең дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләрен һәм элемтәне үстерүне һәм мәгълүмати иминлекне гамәлгә ашыруны җайга сала дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 60 көн эчендә Концепцияне гамәлгә ашыру чаралары планын эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Концепция нигезләмәләренә таянып эш итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларга аңа таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин